Татарстан яшьләре

N 36

(8758)

ПӘНҖЕШӘМБЕ

25 март, 1993 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *



Төркия Республикасы Президенты Тургут Озал Татарстан Премьер-министры М.Сабировны кабул итте. Президент, икътисадны үстерүнең төрек моделенә тукталып, базар мөнәсәбәтләренә күчкәндә Төркиядә вак һәм урта бизнеска зур игътибар бирелгәнлеге турында сөйләсә, Премьер-министр Татарстандагы хәл белән таныштырды, республиканың дөнья дәүләтләре белән киңәя барган элемтәләренә тукталды. Төркия Премьер-министры һәм министрлар белән булган сөйләшүләр барышында күп кенә уртак проектларны тормышка ашыру мәсьәләләре каралды.

Югары Совет сессиясендә халыкны социаль яклау буенча хөкүмәт программасы кабул ителде. Аннан күренгәнчә, 1 апрельдән башлап балаларга, укучы яшьләргә, пенсионерларга һәм инвалидларга 1-2 мең сумлык азык-төлек чеклары биреләчәк, бюджет оешмаларында эшләүчеләрнең минималь хезмәт хакы ике мәртәбә арттырылачак.

Акча арттыру юкка гына түгел, билгеле. 1 апрельдән яңа бәяләр түбәндәгечә булыр дип фараз ителә: сыер ите - 460 сум, дуңгыз ите - 440 сум, кош ите - 420, атланмай - 920 сум, сыек май - 400 сум, йомырка (унысы) - 130 сум, маргарин - 520 сум, шикәр - 260 сум, сөт (литры) - 40 сум. Он, ярма, чәй һәм аракының да бәяләре үзгәрә. Ипинең бәясе шул килеш калачак.

Кичә Татарстан мөселманнары Гает намазына барды. Казанның Мәрҗани, Әҗем, Рамазан, Болгар, Вафа хәзрәт мәчетләрендә иртәнге тынлыкны ярып азан яңгырады. Рамазан шәрифкә багышланган вәгазьләрдән соң Гает намазы укылды. Бәйрәмнәр мөбарәк булсын, диндәшләр!

Чама чамага туры килә...

Мәскәүдә власть өчен ызгыш-тарткалаш башланганга инде менә өч көн узды. Әмма әле моның азагы күренгәнгә охшамый. Хәер, иң көчле матбугат чараларының көнетөне кем җырын җырлавын искә алсак, җиңүнең дә кайсы якта буласын чамалау артык кыен түгел. Чама чамага туры килә ул. Шулай да, артык кыю фаразларга кереп китмичә генә, 26 мартка билгеләнгән гадәттән тыш съездның ни белән тәмамлануын көтеп карыйк...

Мәскәү хакимнәре "халык мәнфәгате" дип төкрек чәчеп талашып ятканда Казан нишли? Казан, татарларча артыгын сөйләшми-нитми генә, халыкны социаль яклау мәсьәләләрен хәл итәргә тырышып ята. 23 мартта Югары Совет сессиясе хөкүмәтнең халыкны адреслы яклау программасын кабул итте. Апрель аенда Россия хөкүмәте иң кечкенә хезмәт хакын ике мәртәбә күтәрергә җыена. Әлбәттә, әлегә "рубль" зонасында яшәгән Татарстанга да моның йогынтысы булмый калмаячак. ХҮ сессиядә ТР Югары Советы минималь хезмәт хакы турында үз законын кабул итте. Ул 4500 сум булачак. Һәрберебез дә бик яхшы белә: әгәр дә хезмәт хакы күтәреләсе булса, кибетләрдәге бәяләр дә буй җитмәслек булып өскә сикерә. Шуның өчен дә халыкны тәмам хәерчелектән саклау өчен махсус программа эшләнеп кабул ителде дә. Үзләрен "чын демократлар" дип санаучы Латыйпов, Султанов, Решетов, Михайлов, Штанин, Грачевларның программаны уздырмаска җан тарткалашуы үзе үк хөкүмәт программасының ярыйсы ук әйбәт документ булуы турында сөйли. Аның бөек бәйрәм - Ураза гаете алдыннан кабул ителүе дә бу зур һәм игелекле эшнең уңай булырына өмет уята. Олылар әйтмешли, иншалла, шулай булыр.

Р.ШӘРӘФИЕВА.

Спикер якташларын котлый

Әлмәт язучылар оешмасы төзелүгә 30 ел тулу уңаеннан Татарстан Югары Советы республикабызның нефть төбәгендә яшәп иҗат итүче әдипләрне, әдәби берләшмәләрне, әдәбият сөючеләрне чын күңелдән котлый. Бу якларда яшәүче язучыларыбыз һәрвакыт республикабызның мәшәкатьле, катлаулы, күп көч һәм хезмәт сорый торган нефть чыгару эшен каләм очында тоттылар, нефтьчеләрнең уй-хисләрен, күңел дөньяларын, борчылу-куанычларын югары әдәби чаралар белән яктырттылар, нефть яклары кешеләре мисалында атаклы әдәби образлар иҗат иттеләр.

Бүгенге олы юбилей көнендә нефть районнарындагы һәр әдипкә, һәр каләм иясенә яңа иҗат уңышлары, исәнлек-саулык, шәхси уңышлар һәм бәхет телим, киләчәктә дә бу якларда югары зәвыклы әдәби әсәрләр иҗат ителер һәм Әлмәт язучылар оешмасында яңадан-яңа талантлы әдипләр үсеп чыгар дип ышанам.

Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф.МӨХӘММӘТШИН.

БЕЛДЕРҮ

Сезне Алмаз ХӘМЗИН белән Камил КӘРИМОВ Беренче апрельгә багышланган зур "Шаян сәхнә"гә чакыра.

Программада шагыйрьләр Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев, җырчылардан - Айдар Фәйзрахманов, Зәйнәп Фәрхетдинова, Рөстәм Сәрвәров, Фәйрүзә Сибгатуллина, Эльмира Вәлиева һәм "Казан кызы" ансамбле катнаша. Тамашачылар өчен 17 сәгатьтән арзан бәяле промышленность товарларыннан ярминкә оештырыла. Зур "Шаян сәхнә" 31 мартта Цирк бинасында 19 сәгатьтә башлана.

Белешмәләр өчен телефоннар: 32-52-23, 32-14-12, 53-07-21.

Томанлы Альбион кунаклары

22 март көнне Татарстанның Тышкы Икътисадый элемтәләр министрлыгы (ТИЭМ) җитәкчесе Шәүкәт Арсланов Казанга эш визиты белән килгән Англия кунакларын кабул итте. Алар - Бөекбританиянең Мәскәүдәге илчелегенең беренче сәркатибе Нигалас Фостер әфәнде һәм икътисадый мәсьәләләр буенча беренче сәркатип - Ли Тернер. Ш.Арсланов һәм кунаклар Татарстанның социаль-икътисадый үсеше турында сүз алып бардылар һәм ике ил арасындагы хезмәттәшлек перспективалары турында сөйләштеләр.

Инглиз дипломатлары Казанда дүрт көн кунак булачаклар. Шушы вакыт эчендә зур промышленность предприятиеләрендә булырга, сәяси фиркаләр һәм хәрәкәтләрнең лидерлары белән очрашырга телиләр. Шулай ук кунаклар башкаланың мәдәни тормышы белән дә танышырга планлаштыралар.

Бүген ТИЭМның конференц-залында Нигалас Фостер һәм Ли Тернер әфәнделәр матбугат конференциясе үткәрәчәкләр. Конференция 11 сәгать 20 минутта башлана. Аның турында киләсе санда укый аласыз.

Равил САБЫР.



17 мартта Россия Үзәк банкы элекке СССР территориясендә барлыкка килгән яңа дәүләтләрнең милли акчаларын котировкалауны башлады. Эстон кронасын алмаштыру курсы - 49,88 сум, латыш акчасына карата - 4,57 сум, 10 украин карбованцы - 2,5 сум. Литва талоннары әлегә бу исемлеккә кертелмәгән.

Ерак Көнчыгыш хәрби округларының берсендәге складтан 800 "кәшә" урланган. Хәрби прокуратура, Куркынычсызлык министрлыгы хезмәткәрләренең уртак эше нәтиҗәсендә, урланган корал табылган. Әлегә билгеле булган информациягә караганда, караклар - контракт буенча хезмәт итүчеләр.

"Взгляд" тапшыруының элекке алып баручысы Владимир Мукусев автомобиль фаҗигасендә чүт кенә һәлак булмыйча кала. Ул утырган "Вольво"ны кинәт кенә каяндыр килеп чыккан "КрАЗ" машинасы бәрдертә. Чит ил машинасының кабыгы нык булганлыктан гына Мукусев исән кала. "К.П." газетасы бу вакыйганы, очраклы хәл булмаска да мөмкин, дип бәяли.

Фараз

Редакция укучыларыбызга тәкъдим иткән уенның шартларын тагын бер кат исегезгә төшерәбез.

Кем дә дә кем киләсе ярты елга "Татарстан яшьләре"нең тиражы күпме буласын барысыннан да төгәлрәк әйтеп бирә, шуңа махсус бүләк тапшырыла. Моннан тыш бу кешегә газетада теләсә нинди фикерен, тәбрикләү сүзен яки реклама бастырып чыгару хокукы бирелә (күләме - машинкада бер бит).

Хатлар 1 майга кадәр кабул ителә. Конверт тышына "Фараз" дип куярга онытмагыз.

* * *

"Фараз"га инде хатлар килә. "Мин үзем киләсе ярты еллыкта "Татарстан яшьләре"нең тиражы 250.000 булыр дип фараз кылам, - дип яза Әтнә районының Күшәр авылыннан Габделнур Халиков, - чөнки халыкның сезнең газетага ихтыяҗы бик зур. Чөнки "Т.Я." иң популяр һәм дә халык яратып укый торган газеталарның берсе. Өставенә, иң арзан һәм дә яхшы газета".

"15 марттан подписка үткәрә башладык (мин элемтә бүлегендә эшлим). Халык беренче булып "Татарстан яшьләре"нә языла" - монысы Актаныш районының Чалманарат авылыннан Нәзифә Хафизова сүзләре.

Рәхмәт яхшы сүзләрегезгә, дуслар! Авызыгызга бал да май! Тик шулай да укучыларыбызны искәртеп куясы килә: язгы мәшәкатьләргә муеннан кереп чумганчы "Татарстан яшьләре"нә язылып калсагыз, күңелегез тыныч булыр.

Газетаның индексы 54121, ярты елга язылу бәясе нибары 294 сум!



Министерство связи СССР
«Союзпечать»

АБОНЕМЕНТ НА ГАЗЕТУ 54121 (индекс издания)

"Татарстан яшьләре" (наименование издания) Количество комплектов:

на 19 ___ год по месяцам:											
1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12

Куда ________ (почтовый индекс) ________ (адрес)

Кому ________ (фамилия, инициалы)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер

НА ГАЗЕТУ 54121 (индекс издания)

"Татарстан яшьләре" (наименование издания)

Стоимость	подписки	___ руб. ___ коп.	Количество комплектов:
	переадресовки	___ руб. ___ коп.	


на 19 ___ год по месяцам:											
1	2	3	4	5	6	7	8	9	10	11	12

Куда ________ (почтовый индекс) ________ (адрес)

Кому ________ (фамилия, инициалы)

Фәнзаман БАТТАЛ

"Ильяс абый, синә килдек..."



Россия Югары Советының съездын караган саен Ильяс үз-үзен битәрләп куя: "Йә, нигә дип вакыт саттың инде бу кәмитне карап?! Башка эшең юк идеме?"

Әйе, күрмәскә, карамаска иде шуларны. Ник дисәң, телевизор ашаган токны да акларлык фикерләре, мәгънәләре юк. Ләкин күз йомып та яши алмыйсың. Чөнки Татарстан - мөстәкыйль Татарстан - шушылар көннән-көн көчәйткән гарасат уртасында. Бер халыкка да (хәтта үз халкына да!) изгелек эшләргә хәле булмаган шовинистларның, төрле төстәге "демократ-дерьмократларның" башка милләтләргә ут салу, фаҗига тудыру өчен мәкерләре хәттин ашкан. Әле аларның азатлыкка омтылган бер генә халыкны да канга батырмый калганнары юк. Шуңа күрә уяу булырга, съездларын гына түгел, сулышларын да аңлап-сизеп яшәргә кирәк!

Уйларын бүлеп, телефон шалтырады:

- Ильяс туган, кабат күңелсезлек: Кирово-Чепецкидан кайткан ике солдатны, богаулап, Минзәлә төрмәсенә алып киткәннәр.

Монысы да Россия биргән "хокук". Мәскәүгә табынучы прокурор рөхсәт биргән, шул ук Мәскәүгә коллык итүче милиция богау кигергән. Менә сиңа мөстәкыйльлек, менә сиңа урыс демократиясе! Югыйсә, халыкара кануннарны истә тотсаң, изге дип санасаң, оккупацияләнгән халыктан солдатка алу - гөнаһлы гамәл.

"Димәк, төп эштән бушаган бер сәгатьтә иртәгә дә кәеф бозарга, егетләрне коткару чарасын күрергә туры киләчәк", - дип, хәтеренә киртләде Ильяс.

* * *

Моннан уналты еллар элек Түбән Камага бер офицер - өлкән лейтенант кайтып төште. Үзе яшь, үзе чибәр, гәүдәсе - батырлар гәүдәсе. Елмаеп, балкып тора. Шушы калада яшәүче туганнары аңладылар: егет тыныч хезмәткә кайткан. Белеменең дә сирәк белем икәнен истә тотып, төрле эш тәкъдим итәргә керештеләр.

Туганнарының, дусларының изге ниятен аңлагач, елмаеп рәхмәт әйтте офицер:

- Ачуланмагыз, тормышны үземчә башлыйсым килә.

Атна-ун көн үтте микән, елтыр погонлы кисемнәрен комбинезонга алмаштырды егет, кулына, кем әйтмешли, киләчәк белән отвертка алды һәм... йортлар төзү комбинатының цехына гап-гади электрик булып эшкә керде. Бер атна үтте микән, икеме - һәр эшне төгәл һәм житез башкаручы егеткә бригадирлык вазифасын тәкъдим иттеләр. Тиздән, цехтагы ир-егетләр өстәге житәкчеләргә үтенеч белән керделәр: барысының да шушы гадел кешенең кул астында эшлиселәре килә икән. Тора-бара коллектив шәйләде - кешеләрнең кайгысын аңлый торган, нахакка рәнҗетелгәннәргә ярдәм итү өчен бернәрсәдән дә курыкмый торган бу ир профсоюз лидеры булырга тиеш! Профсоюз белән ул җитәкчелек иткән елларда эшче халык иркен сулады. Менә хикмәт: фатирлар да, санаторийларга путевкалар да күбрәк бирелә, дачалар төзү өчен җир алу да җиңелләшә...

Ләкин шул чорда "Татэнергострой" тресты башлыклары да аның сәләтен, гамәлен күзәтеп тора. Әнә, бер предприятиенең - төзелүче йортларның стенадан кала барлык деталь һәм җиһазларын ясаучы предприятиенең хәле начар. Эшне җайга салса, мөгаен, "бывший офицер" гына җайга салыр. Тагын бер-ике баскычтан соң алты-җиде ел элек кенә эшкә электрик булып килгән әлеге егет Түбән Камаңы төзүче коллектив җитәкчесенең урынбасары, ягъни эшче-төзүчеләрнең, хезмәткәрләрнең тормыш-көнкүреше турында кайгыртучы, шул берләшмәне кадрлар белән тәэмин итүче.

Ильяс Әгъләм улы Әхиятдинов зурлыгы буенча Татарстанда өченче урында торучы шәһәрдә әнә шундый юл үтте.

* * *

Яхшы атка йөкнең дә авырын салалар, дигәндәй, сәләтле, рухлы кешегә дә халык үзенең ышанычын, өметен йөкләргә тырыша. Шәһәрдә дә, районда да миһербанлык, гаделлек белән абруй казанып өлгергән Ильясның шәһәр Советына депутат булып җиңел сайлануын, бәлки, әйтеп тору да кирәкмидер сыман. Халык аны теләп кенә түгел, яратып сайлады. Аңа кадәр дә милли азатлык өчен көрәшчеләрнең бер лидеры булып танылган Әхиятдинов зур сәясәткә нәкъ менә депутатлыктан атлады. Юк, Югары Совет кына, Президент кына хәл итми Ватанның мөстәкыйльлеген. Аның чын нигезе, ныклы нигезе шәһәрләрдә, районнарда салына. Әйтик, Түбән Кама сессияләрендә Татарстанның мөстәкыйльлеген яклау мәсьәләсе беренче мәртәбә тавышка куелганда йомшаграк рухлы кешеләрнең мөһерге сынса да әллә ни гаҗәп булмас иде. Шовинистик, коммунистик җанлы депутатларның күплеге, аларның Татарстанны һаман да Россия колониясе итеп калдырырга теләве тиз ачыкланды. Башта 120 депутатның нибары 22 се мөстәкыйльлекне хуплады... Ильяс кебекләр өзми-куймый исбатлап килә: һәр милләтнең азат булырга хакы бар, башка халыклар белән тигез яшәргә, үз тапканын үз файдасына тотарга хокукы бар! Шуларның барысын да матбугаттан, җирле радиодан күзәтеп-аңлап яшәүче шәһәрдәшләре, райондашлары Ильяс Әхиятдиновны Милли Мәҗлес рәисе итеп сайладылар.

Ә менә быел шәһәр хакимиятен яңа хәлләр, вакыйгалар сискәндерде:

- "Якын" чит илләрнең армияләрен ташлап кайткан солдатларның шактыен җинаятьчеләр үз якларына аудара. Әгәр дә аларга карата сәясәт элеккечә дәвам итсә, тыныч хезмәт кешеләре булырга тиешле егетләрнең киләчәге куркыныч...

Элекке сәясәт һәркемгә мәгълүм: кайткан солдатларны "акылга утырту, керер тишек калдырмау" максатында эшкә алмыйлар. Янәсе, энекәем, армиягә кире кит, шунсыз сиңа рәхим-шәфкать булмаячак.

Сессиядә Ильясның чыгышы аңларга теләмәүче депутатлар да аңларлык булды:

- Үз иленә кайткан солдат - качкын түгел. Ул егетләр, ул солдатлар үз Ватанына кирәк. Империянең рухи яктан таркалуы кемгә генә сер микән хәзер?! Шовинистлар сеңдергән фикер урыс хәрбиләренең дә аңына сеңде. Шуңлыктан башка милләт солдатларын кыйныйлар, гарипләндерәләр, үтерәләр. Хәер, ялгышрак әйттем әле... Татарстаннан икәнен белсәләр, урыс хәрбиләре урыс солдатларының да гомерен кисәләр. Монысының да мисалларын ерактан эзлисе юк - үзебездә бар.

Хезмәт мөддәтен тәмамламый кайткан солдатларны Түбән Камада хезмәт иттерү, һичьюгы бер-ике батальон булдыру мөһимлеген, егетләрне эшкә дә ашыгыч урнаштыру кирәклеген һәрьяктан дәлилләп, исбатлап бирде Ильяс.

Әлбәттә, тормышта, бигрәк тә мондый болганчык чорда, урысларча әйтсәк, "один в поле не воин". Таянычың, фикердәшләрең, синең кебек үк тәвәккәл затлар булмаса, әллә кая бара алмыйсың. Шулчак күпләрне гаҗәпләндергән, дөресрәге, көтелмәгән хәл булды - Түбән Кама хакимияте башлыгы Әгъдәс Галиәхмәтов солдатларны яклау, йолып калу җаваплылыгын үз өстенә алачагын ачыктан-ачык белдерде. Аннары солдат яшендәге егетләрнең хәлен кайгырту, аларны эшкә урнаштыру һәм яклау буенча махсус комиссия төзелде. Аның җитәкчесе итеп... Ильясны сайладылар.

Хикмәт сайлануда гына булса һәм аларның һәркайсына дәрәҗә итеп карасаң, җиңелдер ул. Җиңелдер... Инде дә һәр йөгенне ихлас күңелдән тартырга тырышсаң, никадәр хезмәт, күпме мәшәкать эчендә кайнарга кирәк! Ә Ильяс аның нәкъ шул вариантын гына белә дә. Богауланган, төрмәгә ябылган солдатларның язмышын да Ильяс бер тәүлек эчендә хәл итте.

Военком белән күзгә-күз сөйләшүдән соң ук Минзәлә төрмәсенә машина чыгып китте. Кичкә таба инде әлеге ике егет Ильяс каршында утыралар иде.

- Йә, егетләр, нишләргә исәплисез?

- Россия армиясенә кире кайту гына булмасын. Һәр эшкә әзер, Ильяс абый.

- Без төзүчеләр отряды оештыра башладык. Шунда барырга ризамы соң?

- Шатланып риза.

... Сүз дә юк, Россия властьларының тотрыксызлыгы аркасында туган бу анархия чире беткәч, Татарстанның үз армиясе оешырга тиеш. Ул чакта инде егетләр, һичшиксез, үз Ватанына хезмәт итәргә тиеш булырлар. Түбән Камада кимендә бер-ике батальон, Чаллыда полк оешыр дип уйлый Ильяс кебек элекке офицерлар. Хәзергә исә егетләрнең хәлен җиңеләйтерлек нинди чара бар - барысы да гамәлгә ярар.

Военкоматта, предприятиеләрдә хаклык тапмаган егетләр Ильясның ишеген көннән-көн кыюрак шакый:

- Ильяс абый, сиңа килдек...

* * *

"Техника йорты" дип йөртелүче мәдәният сараеның 800 кешелек залы килгән аналарны, апаҗиңгиләрне, әбиләрне, кызларны сыйдыра алмады ул көнне. Шәһәр Советы рәисе Владимир Камелин да гаҗәпләнүен яшерә алмады:

- Гаҗәп бу татар хатыннары! Урыс бичәләрен болай җыеп булмый... Юк, булмый...

Дөресен генә әйткәндә, Ильяс үзе дә сокланды. Милли Мәҗлеснең шушы чара хакында киңәшү өчен җыелган утырышында:

- Ике - өч йөз генә ана килсә дә, "беренче коймак" өчен ярап торыр, - дигән иде.

Чәчрәп чыгып сөйләүчеләр дә, елый-елый сөйләүчеләр дә күп булды җыелышта, СССРның таркалганын да белмичә кирегә сукалаучылар да сизелде. Ильяс кебекләр, әлбәттә, әйтер сүзләрен тыныч әйттеләр.

- Артык баласы, сөймәгән баласы булган ана гына Россиягә солдат бирәчәк, - диде Милли Мәҗлес башлыгы үзенең кыска гына чыгышында.

Кайсыдыр хатын кычкырып ук җибәрде:

- Кемнең баласы үзенә артык инде, энем?!

- Артык түгел икән, саклагыз, - дип тәмамлады сүзен Ильяс. - Үз улларыгызны Рәсәй армиясенә сугым малын биргән кебек бирмәгез.

... Инде менә чит ил армияләрен ташлап шәһәргә, районга кайткан солдатлар 200 дән артса, китәргә теләмәүчеләр берничә мәртәбә күбрәк хәзер.

* * *

Әтисенең язмышы Ильясны әледән-әле ачындырып, тетрәндереп тора. Бөтен фикерен, әйтер сүзләрен үз эченә җыеп китте мәрхүм. Әледән-әле бер сүзне кабатлады:

- Әйтер сүзләрем күп, әйтмим генә...

Бары тик бер генә мәртәбә чишелә язды картның теле. Ниндидер сәбәп белән каты гына салган иде ул. Шунда, Ильястан башка беркем дә юклыгына инангач кына, гомер буе күз яше күрсәтмәгән әтисе үксеп куйды:

- Нинди тормыш инде бу, улым, ә? Эчеңдә гомер буе ут йөрсен, шуның төтенен дә чыгарырга ярамасын! Килер бер көн, килер: үзләре төкергән алланы да эзләп табарлар, үзләре җимергән мәчетне дә кире салырдай булырлар. Әмма соң булыр!..

Аннары тагын сулышын кысты:

- Һай, әйтер сүзләрем күп, әйтмим генә.

Шөкер, безнең заман әйтер сүзләрен яшермәскә өйрәнеп бара. Милләт уяна, аны милләтнең үз уллары, үз кызлары уята. Ильясның күңелендәге горурлык тантанага да әверелә кайчак. Шушы калада гына да күпме бит газиз милләте өчен янып-көеп йөрүче кешеләр. Түбән Каманы гына түгел, бөтен Татарстанны сокландырган халык депутаты Азат Зыятдинов, Татар иҗтимагый үзәгенең җирле координаторы Хәлил Әюпов, "Иттифак" фиркасе рәисе Рәшит Фәйзриев, дин башлыгы Мәүлетҗан Сибгатуллин... Бер-береңә нык лап таянырдай мондый затлар булганда, милләтнең үсүенә дә, тулы азатлык яулавына да шик юк.

"Мәчетне дә кире салырдай булырлар..." Әтисенең бу сүзләре бер таләп, үтенеч кебек яшәде Ильясның зиһенендә. Минзәләнең Гөлек авылы - туган авылы мәчетсез күпме утырыр?

Башта Гөлеккә Мәүлетҗан хәзрәт белән кайтуны хуп күрде Ильяс. Үзара киңәшә торгач, Хәлил Әюпов та кайтырга теләк белдерде. Алдан игълан элдерткәннәр иде - өчесе - Түбән Кама кунаклары килүгә клубта алма төшәрлек урын да калмаган иде инде.

- Ярдәм итү нияте белән килдек, авылдашлар, - дип сүз башлады Ильяс. - Әлбәттә, төп авырлык үзегезгә төшәр. Ләкин без проект белән дә, төзелеш материалларының арзаны белән дә булышырбыз. Транспорт та бирербез.

Халык, гүя, дистә еллар буе шушы сәгатьне генә көтеп яшәгән - мөлдерәмә тулган күңелләр түзмәде, шатлыктан елаучылар да күренде.

Төзү материаллары белән ярдәм итүне вәгъдә иткәнче Ильяс "Түбән Кама Гумилевы" дип йөртелүче, халык ихтирамын яулап өлгергән Юрий Константинович Рачков белән сөйләшеп килгән иде. Шәһәр төзүчеләренең башлыгы, халык депутаты. Ильяс аңа авылдашларының хәл-әхвәлен, ярдәмгә мохтаҗ булуларын сөйләде. Гөлектә ул көнне мәчетнең урынын да билгеләделәр. Инде монысына да куана Ильяс: туган авылы, Түбән Кама ярдәмен дә тоеп, мәчет сала!

* * *

Милләт һәм Татарстан бәйсезлеге өчен бинһая эшләр башкарса да, Ильяс Әхиятдиновның төп һөнәре - төзүче, төгәлрәк әйтсәк, төзелешнең хәлен, төзүчеләр тормышын кайгыртучы. Монда да күңелгә хуш килерлек уңышлар арта тора: әле биш-алты ел элек кенә коллективның нибары сигез, бик күп дигәндә унике кешесе фатир алу бәхетенә ирешә ала иде. Хәзер исә ел саен 60-70 кеше яңа фатирга күчә. Кайбер урыннарда төзелешләр туктап калган чорда да "Нижнекамскпроектстрой" төзүчеләре йортлар салу темпын арттыра бара. Әйтик, әле өченче ел гына коллектив 71.000 квадрат метр торак мәйдан (1000 квартирдан артык!) төзегән булса, быелтыр бу күрсәткеч 79.000 гә җитте.

Билгеле, милли бәйсезлек өчен көрәшче турындагы язманы шушындый коры саннар, мәгълүматлар белән төгәлләүне сизгәч, кайбер укучының хәтере дә калыр. Әмма, Ильясның үз сүзләре белән әйтсәк, болары да азат халыкның киләчәге өчен эшләнә. Ягъни: хәерче ирекледән бай ирекле бәхетлерәк, дөнье...

ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки)

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ — МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

13нче БАГАНА

Савиново тирәсендә яшәүчеләр тиенде рәхәткә: прәме юл өстенә ике машина чөрек мандарин аударып киттеләр. Олысы-кечесе шунда казына. Кибеттән 400 сумга ала алмаганны чүплектән ташып рәхәтләнде ярлы бәндә. Кибет киштәләрендә черен ятучы лимон белән әфлисунны да шул язмыш көтә булыр. 500-400 тәңкәдән ала алмаучылар аларын да чүплектән җыеп чәй эчәргә өметләнәләр әле.

Ш.РӘХИМ.
Казан.

* * *

Минем төп чыгышым - Казан ягы. Гомерем буе мәгърифәтчелек белән шөгыльләндем. Дару үләннәренең файдаланышы турында йөзләгән мәкаләләр авторымын. Үземдә дә халык табибына хас сыйфатлар бар, шөкер. Әйтик, дару үләннәре ярдәмендә ярты сәгать эчендә иң югары кан басымын да нормаль хәлгә китерә, теш сызлавын баса алам. Һавада йөзгән болытларның юнәлешен кирегә үзгәртә алам. Хөрмәтле редакция! Мин үз серләремне тик сезнең белән генә уртаклашам. Моның үзенә күрә сере бар. Чөнки сезнең газета башкалардан өстен тора. Ул, башкалардан аермалы буларак, акыл өйрәтми, ә үзенә җәлеп итә.

Феликс ФӘТХИЕВ.
Башкортостанның Дүртөйле районы, Йосып авылы.

* * *

"Т.Я."нең 24 нче санында Агыйдел каласыннан, түшәм тактасы тиз черемәсен өчен аның өстенә нәрсә җәяргә, дип сораган Хәмит Шәрәфиевкә: матча башларына иң әүвәл яхшылап сус кыстырыла, аннары түшәм тактасына кәгазь җәеп, шлак белән пычкы чүбен кушып саласың (20-25 см. калынлыкта). Болар урынына торф та ярый. Әмма ком белән балчык ярамый - өйне парландыра.

Мөхәррәм НУРИЕВ.
Зеленодол районы, Молвино авылы.

* * *

"Т.Я."не мин 1958 елдан бирле алам. Аның һәрбер сүзен укып барам. Аны укысам, яшьлегемә кире кайткандай булам. Газета килсә, авылыбызга Фәнзаман яки Әлфия Самат, Равил Сабыр - кайсы булса да берсе килгән кебек тоела. Пенсиядә булсак та, хакыннан тормыйбыз, язылабыз. Без күмәкбез, көчлебез, без "Т.Я."нең запастагы терәгебез.

Сезнең иҗат эшегездә зур уңышларга ирешүегезне теләп,

Авзах ГАЗИЗОВ.
Башкортостанның Дүртөйле районы, Тайморза авылы.

ТӨП ДОШМАНЫГЫЗ ТАТАРМЫ?

Татар теленең Башкортостанда дәүләт теле статусын алырга тиешлеге анда милләттәшләребезнең башкорттан ике-өч мәртәбә күбрәк булуына гына бәйләнмәгән.

Башкортостан - могҗизалар иле

Бер миллион ярым татар халкы яши торган Башкортостан республикасы бар. Шул милләттәшләребез, ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, туган телебездә дистәләгән район һәм зур күләмле бер республика гәзите ("Кызыл таң") чыгара, әмма сугыштан соңгы дәвердә монда бер генә татар язучысы да иҗат итеп яшәгәне юк. Хәтта татар язучысы булып мәйданга чыккан С.Кудаш, М.Сөндекле, Й.Гәрәй, Г.Гомәр кебек каләм ияләре дә ниндидер могҗиза белән бер заман милли мәдәниятебез күгеннән юкка чыктылар. Әмма мине тагын да сәеррәк, тагын да баш җитмәслек бер күренеш озак еллар аптырашка салып килде: кеше татар гаиләсендә туа, татар мәктәбендә һәм югары уку йортларының татар теле-әдәбияты бүлегендә укый, хәтта яшь буынга татар теле-әдәбиятыннан сабак бирә, аннары шул ук милләттәшләребезгә адресланган район яки республика татар гәзитләрендә эшли, аларның мәдәният бүлеген озак еллар җитәкли, ләкин әдәби әсәр язды исә, башкорт язучысына әйләнә дә куя! Ә.Атнабаев, Ф.Богданов (Г.Ибраһимовның авылдашы!), Ф.Гомәрев, Ф.Габдрәхимев һәм башкалар әнә шундый "алхимия" тегерменәнә эләгә. Газиз милләтләреннән кем аерды икән аларны: алхимия тегерменеме, расизммы? Нишләп әле бер миллион ярым татарның үзе яшәгән республикада милли әдәбиятын тудырырга хакы юк? Саны алтмыш мең тирәсе балкарның утыз язучысы бар, туксан меңле абхазның - тагын да күбрәк. Ә шулардан унбиш-егерме биш тапкыр артыграк санлы милләттәшләребез берне дә үстерә алмый!

Уфага алтмышынчы елларда баруымда мин "Кызыл таң" редакциясендә шушы хакта Әнгам Атнабаев, сиксәненче елларда Фәрит Габдрәхимев белән сөйләшергә тырыштым. Беренчесе юморист икән, сүзне уен-көлкегә борып җибәрде, икенчесе Башкортостанның үзенчәлекле сәяси һәм мәдәни үсеш шартлары белән таныштырырга тырышты.

Мәсьәләнең төбенә карасаң, Башкортостанда татар әдәбияты һәм сәнгате үстерелмәү һич тә "башкорт милләтчелеге" белән генә аңлатыла алмый. Мәскәү абзый кирәк тапса, ярты миллион башкортны гына түгел, илле миллион украиннарны да бик әйбәт авызлыклый килде. Әгәр теләсә, ул абзый татарны кысарга маташкан берничә дистә башкорт "зыялысын" Себердәге яки бүтән бер лаеклы җирдәге "курортка" озатуны төчкерми дә гамәлгә ашыра алыр иде. Чынлыктагы саны татарга карата егермегә бер нисбәтендәге башкортлар безгә үзбаш күсәк күтәрүне ялгыш та уйлый алмый иде. Димәк, төп сәбәп без телгә алудан сакланган Компартия Үзәк Комитетында, СССР хөкүмәтендә, аларның бөтен телләрне, мәдәниятләрне, милләтләрне бергә кушып, зур "совет халкы", "совет культурасы" барлыкка китерү сәясәтендә иде. Асылда бу эшчәнлек күп гасырлар буена дәвам итеп килгән гап-гади урыслаштыруга кайтып кала иде. РСФСРда моңа иң зур каршылык күрсәтүче көч, табигый ки, мул тарихи тәҗрибәгә ия һәм чагыштырмача күбрәк санлы татар икәнлеген, аны сытып ташламыйча, бүтән кавемнәрне дә юк итеп булмаячагын Мәскәү абзый күптән белә иде. Һөҗүм татарны бүлгәләүдән, әүвәл Татарстаннан тышта калган милләттәшләребезне аңгырайтудан башланды. Үзен күләгәдә, ак вә пакь калдыру өчен, татарның җелеген суыру эшенә ул бүтән азчылык милләтләрне тартырга омтылды, беренче нәтиҗәләргә ирешү дәверендә аларга татар хисабына бераз бөтәергә дә юл куйды. Татарны йоткач, яңа һөҗүм үзләренә ясалачагын, аларны әнә шулай бөрәм-бөрәм юк итү ансат булачагын уйлап та карамаган яки алдан ук колонизатор ихтыярын үтәргә аңлы рәвештә яллаган "башкорт шовинистлары" менә шундый шартларда "егетлек" күрсәтте, гайрәткә һәм көч-куәткә ия булды.

Таяк ике башлы ул...

Үзгәртеп кору совет милли сәясәтендә шовинистларга һәм ассимиляторларга бик нык китереп сукты, бу хәл Башкортостан татарларын да билләрен турайтуга этәрде. Әмма татарны зәгыйфьләндерү эшчәнлегенә тартылган, Мәскәү тарафыннан астыртын рәвештә иркәләп-назлап асралган башкорт милләтчеләре дәирәсе пычрак шөгыле белән шул чаклы "мавыккан" иде ки, әле дә әхлаксыз, киләчәге өметсез көрәштән айнып бетә, кире чигенә алмый. Ул гомумтөрки мәнфәгатьләргә зыян китерүен, димәк, ахыр чиктә үз тамырына да балта чабуын төшенми. Әгәр яңа Сталин туып, бүгенге Татарстанны, Чувашстанны, Мордовстанны, Түбән Новгород һәм Пенза өлкәләрен дә эченә алган зур Башкортостан төзесә, әлеге дәирә, бик ихтимал, шушы яклар телен дә "башкорт теленең көнбатыш шивәсе" дип игълан итәргә һәм андагы мәктәпләрдә башкорт телен укыта башларга омтылыр иде. Милләтнең акылы тиле нәфесен чикли белүдә дә күренә. Сугыштан соң литовларга Германиядән тартып алынган Кенигсберг өлкәсен үз республикаларына кушарга тәкъдим иткәннәр, диләр. Әмма алар күршедәге ят җирләрне "йотарга" теләмәгән, шуннан соң әллә кайдагы РСФСР составында Калининград өлкәсе барлыкка килгән. Минемчә, литовлар илләрен киңәйтмичә бик дөрес эшләгән. Алманнар киткәч бушап калган җирләргә иртәме-соңмы СССРның бүтән тарафларыннан төрле халык агылып киләчәген, шуннан соң киңәйгән Литвада литовларның нисбәте кимиячәген, моның исә якын арада ук милли мөнәсәбәтләрдә күп төрле кыенлыклар тудырачагын ваемлы халык вакытында фараз кыла алган.

Фәләненче гасырда безнең халык фәлән җирләрдә дә яшәгән дип, республикаң чикләрен үткәнгә карап киңәйтергә маташу, минемчә, гафу кылынмаслык акылсызлык. Гамәлдә бүгенге чынбарлыкны истә тоту яхшы. Киң мәйданда бүтән халыклар эчендә ун процент нисбәтендә калганчы, кечерәк мәйданда туксан яки һич югы илле процент тәшкил итеп яшәү хәерлерәк. Бары соңгы очракта гына милләт куәте уңай нәтиҗә бирмәячәк интектергеч көрәшкә - үз хосусиятеңне саклау тырышлыкларына тотылмаячак. Аннары... башкаларны йоту хисабына арту, һичшиксез, бәхетле булу дигән сүз түгел. Мисалы - урыслар!

Егет булу җиңелме?

Татар-башкорт арасын бутаучыларның аңлы яки аңсыз рәвештә колонизаторларга хезмәт итүен, һәр ике тугандаш халыкка зыян гына салуын без тоталитар режим шартларында ачыктан-ачык фаш итә алмадык. Әхлаксызлык, идеологик террор чәчәк атканда кайберәүләр татарның донор гына булырга тиешлеген табигый закончалык рәвешендә кабуллады һәм шуңа бирелеп хезмәт итә башлады. Чөнки шул юлдан атлау өзлексез китаплар бастырырга, дәрәҗәле вазифалар биләргә, лауреат һәм депутат булырга мөмкинлек бирәсен алар бик тиз чамалап алды. Иҗатына якты киләчәк тәэмин итәр өчен яңа заман "йомышлы татарлары", җиде бабасыннан ары китеп, нәселеннән башкорт каны эзләргә керешге, үзен аеруча зирәк акыл иясе санаган берсе поляк журналына хәтта: "Октябрь революциясе булмаса, башкортны татар йотып бетерәчәк иде", дип сару кайнатты. Искиткеч елгырлык! Әмма җирәнгеч спекуляция, газиз халкына гына түгел, үзе лакейларча тәлинкә тоткан башкортка да оятсыз хыянәт иде бу. Чөнки "татарлашкан башкорт" бүген дә башкорт әдәбиятын рәхәтләнеп укый, җырын да яратып җырлый, ә менә "игелекле Октябрь революциясе" нәтиҗәсендә татарлашмаган, бары урыслашкан гына башкортка берниндн төрки культура кирәк түгел. Үзен мисалы юк акыл иясе санаучы "йомышлы татарлар" моны күрмәгәнме, аңламаганмы, белмәгәнме? Юк, алар иманнарын иблискә сатканнар иде.

Иблис туй иткәндә иҗат мәйданына атлаучыларга беренче шарт итеп, бисмилла урынына Ленинны, компартияне, икейөзле интернационализмны мактау таләбе куелганда, бөтен барлыгы белән моңа каршы каләм ияләре дә йола такмакларын язарга мәҗбүр булды. Әмма аларның байтагы беркайчан да "россиянмын", "башкортмын" дип лаф орута барып җитмәде. Шуның аркасында аларны китап нәшрияты да, дәрәҗәле вазифалар һәм исемнәр дә, орден-медальләр һәм лауреатлыклар да үз итмәде. "Бердәм совет халкын" укмаштырып маташкан режим исә гомумән аларны, фатир, дача, иҗат йортларына путевка, чит илләргә командировка өләшеп, мактап мәшәкатьләнмәде. Аларга җан сакларлык хәер дә бик җитә, дип киңәнде.

Татарның хокукларын, шул исәптән, үз әдәбиятын туган-үскән җирендә барлыкка китерү хокукын дәгъвалаучыларга әле бүген дә җиңел түгел. Шушы авыр юлдан каһарманнарча атлаган Йосыф Гәрәебез алгы сызыкта торып вакытсыз һәлак булды. Тәвәккәл Айдар Хәлим фикердәшләренә мәйданны киңәйтер, үз маңкортларыбызга һәм ят авантюристларга каршы тагын да нәтиҗәлерәк каршы торыр өчен, Татарстан яшьләре башкаласы Чаллыга килеп, әдәби журнал чыгара башлады. Уфада исә татар язучысы булып яшәр өчен төрле корбаннар бирергә әзер Фәрит Габдрәхимев мәйдан тота. Аның тирәсенә шундый ук каһарманнар, сәләтле яшьләр җыела.



Кичә генә килмәдек!

Халыкның михнәтле тормышында хәл итәсе катлаулы мәсьәләләр кала бирә. Шуларның берсе, әдәбият яшәве өчен хәлиткеч әһәмиятлесе - Башкортостанда татар теленә дәүләт теле статусы бирү. Моңа каршы чыгучылар арасында Татарстан милли хәрәкәте юлбашчылары да булу аеруча сәер һәм шаккатыргыч. Минемчә, бу аларның мәгълүматы чикләнгән, уйларының җитлекмәгән булуы нәтиҗәсе. "Без - сәясәтчеләр!" дип шапырыну, гамәлдә хата арты хата җибәрү хәтта аларны да бизәми.

Татар теленең Башкортостанда дәүләт теле статусын алырга тиешлеге анда милләттәшләребезнең башкорттан ике-өч мәртәбә күбрәк булуына гына бәйләнмәгән. Төп критерий - аның бу республикага үз җире белән керүендә, анда автохтон, җирле милләт булуында.

...Мәгълүм ки, Таншихай җитәкчелегендәге сәнбиләр тарафыннан җиңелгәч, сөн гаскәре калдыклары 155-158 елларда Үзәк Азиядән Идел-Урал буйларына килеп сыена. Тарихи чыганакларда төгәл хәбәрләр булмаса да, борынгы төрки кабиләләрнең Идел-Урал буйларына элегрәк тә, соңрак та күчеп килүләренә шикләнмәскә мөмкин. Хәзерге Башкортостан җирендә дә күренекле эз калдырган сөннәр (шул исемдәге елганы гына искә алыйк) һәм бүтән борынгы төрки кабиләләр арасында бүгенге татарларның да бабалары булган. Әлегә бер шарлатанның да :" Сөннәр - башкортларның гына бабасы" дигәне юк, дисә дә, ул моны исбатлый алмаячак.

Соңрак бу якларга яңа төрки кабиләләр, әйтик, болгарлар һәм кыпчаклар үтеп керүен фән өзлексез раслап тора. Барлык шул кабиләләр составында бары тик башкортларның гына бабалары булган, дисәләр, көлке генә кубар иде. Ә менә "алар арасында татарларның да бабалары булган", дигән фикергә бер җитди галим дә каршы килмәс.

Шунысы бигрәк тә игътибарга лаек: ни өчендер, хәзерге Башкортостан составына кертелгән җирләрдә без соңгы гасырлардагы күченүләргә генә төртеп күрсәтергә яратабыз. Күрәсең, бу кемнәргәдер үтә файдалыдыр. Ә менә шушы төбәкләрдә Таншихай дәвереннән алып, яки аннан да элгәреддән килеп гомер иткән төркиләр, шулар арасындагы бүгенге татарларның ата-бабалары булуы, соңрак шулар нигезендә Идел-Чулман-Агыйдел-Каридел буйларындагы тоташ мәйданда Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы дәверендә һәм соңгырак заманда татар халкы, татар милләте формалашуы - тарихи хакыйкать. Бер үк җирләрдә төрле төрки кабиләләрнең күчмә тормыш алып баруы, төрлесенең төрле дәрәҗәдә уртак үзәк тирәсенә тупланувы, төрле дәвердә утрак тормышка күчүе гаҗәп түгел. Уртак моңнар, уртак дастаннар, уртак табышмаклар һәм мәкальләр очраклы рәвештә генә барлыкка килмәгән - татар белән башкорт туганлыгы бик тирәннән, бик ерактан килә. Шул ук вакытта Евразия киңлекләрендә татарның төп рольне уйнавын, аның монда, шул исәптән, хәзерге Башкортостан җирендә дә ким дигәндә ике мең еллык тарихы булуын танымаска тырышу - тарихи һәм сәяси сукырлык. Хәзерге Башкортостанның көнбатышы һәм аңа күрше төбәкләр - безнең асыл тарихи ватаныбыз, моны 17-18 нче йөзләрдәге миграция, күченүләр белән генә нигезләргә тырышу - беркатлылык. Әгәр Башкортостан башкортлар күпчелек тәшкил иткән җирләрне генә эченә алган булса, анда бер телнең - башкортчаның гына дәүләт теле булуы каршылык уятмас иде. Әмма сталинчыл шовинистлар егерменче елларда татар халкына тарихи ватанында бер дәүләттә тупланырга юл куймады, аның үзбилгеләнү хокукын таптап, кырый төбәкләрен төрле өлкәләргә һәм республикаларга, җөмләдән, зур гына өлешен Башкортостанга кисеп бирде. Башкортны чамадан тыш яратканга түгел. Киресенчә, Зәки Вәлиди хөкүмәтенең "артык милли рухлы" булуын, Кече Башкортостанда башкортларның зур күпчелек тәшкил итүен, шунлыктан монда чын милли башкорт дәүләте аякка басуыннан хәвефләнеп, ул Кече Башкортостанга нигездә татарлар һәм урыслар яшәгән Уфа губернасын кушты, зур Башкортостанда башкортларны азчылыкта калдырып, вәлидичеләрнең өметләрен челпәрәмә китерде. Шуның белән бергә кардәш халыклар дуслыгына да менә дигән мина салып куйды. Сталинчылар фаразлавынча, алар үзара көрәшеп, икесенең дә урыслашуына карышасы көчләрен исраф итәргә тиешләр иде. Кызганыч ки, өметләре акланды!

Татарстан республикасының булуы безгә аннан тышта яшәүче милләттәшләребез мәнфәгатен онытырга, бигрәк тә, кемнәргәдер яхшатланып, юмартланып, аны корбан итәргә - туган халкыңа зарарлы белдерүләр ясарга, алыш-биреш итәргә хокук бирми. Безгә яхшылык теләмәүче көчләр нинди генә капкыннар куймас, нинди генә хәйлә-мәкер кулланмас, басым ясамас - алар гамәлен башта ныклап анализларга, максатларын ачыкларга, шуннан соң гына җавап адымнарын атларга кирәк. Башкортостан татарлары теле һәм әдәбияты үсеше, Урал буендагы милләттәшләребезнең киләчәге бары шул очракта гына гадел хәл ителә ала.

Без бүген дә әле шактый нәрсәләрне аңлап бетермибез, ихтыяр көчебезне бер йодрыкка туплау да җитешми. Күпләр әле дә корсак колы, кием калыбы гына булудан бушамый. Вакыт исә көтми, егерменче йөз азагында алдынгы милләтләр яхшырак һәм матуррак яшәү өчен бердәм һәм эзлекле рәвештә көрәшә. Бу эш татарга да харам түгел!

Тәүфикъ ӘЙДИ.



ТАТЭКОБАНК

Икътисади үсеш Татар акционерлык банкы

"Татэкобанк"

тел. (8432) 35-16-41

Оперативлык, клиент каршында җаваплылык - безнең эшнең максаты.

Безнең банк акционерлары - "Мелита" акционерлык җәмгыяте, "Татметалл" фирмасы, Химия комбинаты, "Татснаб" акционерлык җәмгыяте, Татоптпродторг, Киез итеккиез комбинаты, КМИЗ, Вакуумmaш һ.б.

"Татэкобанк"


- исәп-хисап һәм агымдагы счетлар ача;
- бөтен төр банк хезмәтләре күрсәтә;
- предприятиеләрнең һәм халыкның вакытлыча тик ятучы акчасын килешенү буенча 40-80 процент дивиденд бирү хисабына кабул итә.

Әгәр дә сез эшлекле һәм үзара файдалы хезмәттәшлеккә омтыласыз икән, "Татэкобанк" Акционерлык банкына мөрәҗәгать итегез.

Безнең адрес: 420104, Казан, Бертуган Касыймовлар урамы, 45.

Телефоннар: 35-29-24, 35-16-41, 35-34-43.

"Татэкобанк"ның филиалы түбәндәге адрес буенча эшли: Казан, Эсперанто урамы, 45.



ТАТИНФРАБАНК

Став клиентом нашего банка Вы внесете свой вклад в развитие инфраструктуры Республики Татарстан!

В нашем банке Вы найдете:

- надежное, качественное обслуживание в течение всего рабочего дня
- бесплатное открытие счетов юридическим лицам
- самые высокие в Казани процентные ставки по личным вкладам

Ваши ежегодные доходы составят:

90% - по детскому накопительному вкладу

100% - по срочному накопительному вкладу

130% - по срочному целевому вкладу в случае потери работы

Для участников, инвалидов ВОВ и инвалидов с детства - дополнительные льготы.

Надежность, оперативность, честность - основные принципы работы "Татинфрабанка" с партнерами.

Адрес: ул.Ленина, дом 8, главпочтамт, ком. 203.

Телефоны: 38-41-52, 38-36-30

Котлыйбыз!

Газетада котлау турында белдерү бастыру өчен редакция счетына 1000 сум акча күчерергә һәм акча күчерү турындагы квитанция белән котлау текстын редакция адресына җибәрергә кирәк. Хатларыгызны бер ай алдан җибәрүегезне сорыйбыз.

* * *

Чувашстанның Батыр районы, Кызыл Чишмә авылында яшәүче яраткан кешебез Замир Азизовны туган көне белән чын күңелебездән кайнар котлыйбыз. Эшеңдә зур уңышлар, алдагы тормышыңда олы бәхет, көтелмәгән шатлыклар, корычтай нык сәламәтлек, озын гомер телибез. Беркайчан да кайгыларга бирешмә.

Иң изге теләкләр белән: хатының, улың һәм кызың.

* * *

Арча районы, Иске Төрнәле авылында яшәүче апабыз Өнзия һәм энебез Рамилнең март аенда туган көннәре. Без аларны олы бәйрәмнәре белән чын күңелдән тәбрик итәбез, кайгыхәсрәтсез көннәр, озын гомер, ныклы сәламәтлек, бәхет, шатлыклар телибез.

Иң изге теләкләр белән: Римма һәм Зөфәр.

* * *


Башкортостанның Краснокама районы, Бачкитау авылында яшәүче Динә Гәрәеваны 55 яшь тулу уңае белән котлыйбыз!

Иң изге теләкләр белән: сеңлең, киявең.

* * *

Чирмешән районының Иске Кади авылында яшәүче әниебез Тәзкирә Булатовага бүген 60 яшь тула. Әтиебезгә гыйнвар аенда 65 яшь, ә аларның бергә гомер итүләренә 40 ел булды. Әти-әниебезне бәйрәмнәре белән котлыйбыз, корычтай нык сәламәтлек, исәнлек-саулык, кайгы-хәсрәтсез гомер итүләрен телибез.

Иң изге теләкләр белән: балалары.







Мәркәзебезнең цирк бинасы тирәсендә кабат ыгы-зыгы башланды, озаккарак сузылган тәнәфестән соң бинаның янә үз тамашачылары җыелды. Бу көннәрдә циркта "Кабаннар һәм селәүсеннәр" исемле программа белән Мәскәү циркы артистлары чыгыш ясый. Кабаннар һәм селәүсеннәрне, акробат һәм клоуннарны күрергә теләсәгез, сез дә циркка килә аласыз - тамашалар ай буе дәвам итәчәк.

Рәсемнәрдә: "Кабаннар һәм селәүсеннәр" исемле цирк программасының кайбер эпизодлары.

Е.КАНАЕВ фотолары.



Баш мөхәррир
Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ
(53-52-34)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2.
"Татарстан яшьләре"
ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сәркатип,реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сәяси тормыш һәм тәрҗемә, фән һәм мәгариф
53-07-56 - мәдәният-сәнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - ВЛКСМның республика оешмасы, Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 4-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Редакциянең исәп-хисап счеты:
Р/с 700161998/700751
ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани,
МФО 265005
Индекс - 54121
Тираж - 200.000

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе. Газета басылуга кул кую график буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 14 сәгатьтә кул куелды. Заказ 6069